Бөтендөнья балалары, дуслашыгыз!

САБАНТУЙ

13 декабрь, 1995 ел.
№ 97-98
(4709-4710)

БАЛАЛАР ҺӘМ ЯШҮСМЕРЛӘР ГАЗЕТАСЫ



ИЛДӘ НИЛӘР БАР ИКӘН?


ФӘННИ БӘЙГЕДӘН — ҖИҢҮ ЯУЛАП

ҖӨМҺҮРИЯТЕБЕЗДӘ «Яшьләр турындагы закон» кабул ителгәнгә ике ел вакыт узды. Ул арада Татарстанда яңа канунны тормышка ашыру, сәләтле балаларны барлау, аларга ярдәм иту буенча күп кенә эшләр башкарыла. Әле яңа гына ноябрьдә Казанда үткәрелгән мәктәп укучыларының фәнни-гамәли конференциясе дә шундыйларның берсе иде.

Анда Казанның Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге укучылары иң актив, иң уңышлы катнашучылардан булды. Һәм бу очраклы хәл түгел, чөнки яңа канун матбугатта басылуы белән педагоглар, ата-аналар, укучылар арасында тәгаенләп өйрәнелгән, киләчәктә нишләргә кирәклеге турында сөйләшенгән, эш планы төзелгән иде. Әйбәт фикерләр әйтеп, яхшы планнар төзеп, аяныч ки, тормышка үтәлмичә калганнары да очраштыргалый бит әле. Бәхеткә каршы, Ш. Мәрҗани исемендәге гимназия җитәкчесе бу җитди мәсьәләне һәрвакыт күз алдында тота. Биредә сәләтле балаларны барлап торалар, аларга арытабан үсү өчен уңай шартлар булдыралар, ярдәм итәләр. Кирәксә, бу мөһим эшкә балаларның ата-аналарын, төрле-төрле белгечләрне, һөнәр ияләрен чакыралар. Шундый зур игътибарны тоеп укучы балалар үзләре дә тырышалар. Тырышкан — ташка кадак каккан, дигәндәй, татар гимназиясенең тырышлыгы да әйбәт кенә нәтиҗәләр бирә башлады инде. Татарстанның Мәгариф министрлыгы, яшьләр эше буенча дәүләт комитеты, Казан дәүләт университеты тарафыннан үткәрелгән әлеге конференциядә Ш. Мәрҗани исемендәге гимназиядән дистәләгән укучы катнашты. Үзләренең фәнни хезмәтләрен җюридәге галимнәр карамагына гына тапшырып калдырмыйча, үз фикерләрен яклап, эчтәлекле чыгышлар ясадылар. Кирәк чагында бәхәсләшүдән дә тартынмадылар. Хезмәтләренең нәтиҗәсе дә куанычлык. Гимназиядән тугыз укучының фәнни эшләре иң дәрәҗәле, мактаулы урыннарны яулап, истәлекле бүләкләргә лаек булды. Өлкән сыйныф укучыларының фәнни эшләре үзләренең заманча эчтәлекле, тирән мәгънәле, мантыйк яктан камил булулары белән аерылып торганлыгы билгеләнде. Мәсәлән, унынчы сыйныф укучысы Ләйсән Җәләлетдинованың хокук фәне буенча (укытучы — Мәгъсүм Насыйбуллин) Берләшкән Милләтләр Оешмасына язган хат-мөрәҗәгате беренче урынны алып, диплом белән бүләкләнгән икән, бу очраклы түгел, әлбәттә. Чөнки бу гимназиядә укучы үсмерләр хокук фәнен бик теләп, югары билгеләргә генә үзләштерә. Бу фәнни-гамәли конференциядә дә чагылды.

Гимназия шәкертләреннән Хәйдәр Камалетдинов, Лилия Сафина, Рәшит Садыйков, Нияз Нәгыймов, Алсу Вәлиеваларның төрки әдәбиятларга, Сөмбел Гаффарованың Идел буе халыклары тарихына, Диләрә Сафинаның табигатьне саклау, Лилия Бариеваның чит телләрне өйрәнүгә багышланган хезмәтләре дә истәлекле бүләкләр белән югары бәяләнделәр.

Сәләтле яшьләренең уңышлары гимназия коллективын, ата-аналарны, барлык укучыларны куандырды. Ә җиңүчеләр исә апрель аенда узачак икенче бәйге — конференциягә әзерләнә.



А. КОЛСАНОВ фоторәсеме.

КЫШ ЭНҖЕГӘ БАЙ

БҮГЕН көн әйбәт кебек иде, көндез кояш чыкты, кар өсләре бик матур булып ялтырап ятты. Кичкә таба гына бертуктаусыз җил күтәрелде. Йомшак, ак мамык кебек кар ява башлады. Буран күтәрелде. Җил берьюлы кар белән уйный, аны туздыра, өйләргә, кибәннәргә китереп сылый, өя башлады. Чыннан да, кышкы суыкта рәхәт тә шул. Мин үзем кышны бик яратам. Без чаңгы белән урманга баргач, табигатьне күзәттек. Шунда җирдә яткан ап-ак карны кулга алып карадык. Карда нинди энҗеләр бар микән дип, кабат-кабат тотып йомарладык. Таудан чаңгы белән ак йомшак кар өстеннән очтык. Без кышны бик яратабыз.

Гөлләрия СӘХӘПОВА.
«Серле каләм» түгәрәге әгъзасы.
Актаныш, Югары Богады.

АК ШӘЛЛЕ ДӨНЬЯ

Күбәләк кар ява бүген тышта,
Дөнья ап-ак шәлен ябынган.
Изүләрдән кереп уйный буран —
Ахрысы, кыш безне сагынган.

Дуслар белән бергә җыелышып,
Без китәбез чана шуарга.
Шундый рәхәт тышта уйнаулары,
Өлгермибез хәтта туңарга.

Альмира ИСХАКОВА.
Арча, Казанбаш.

КАР БӨРТЕГЕ

Табигатьне бизи ап-ак карлар,
Кышкы салкын түгел безгә.
Тәрәзәмә килеп кунды әле
Кар бөртеге — кышның гүзәле.

КУНАК БАБАЙ

Ак сакаллы кыш бабай
Килде кунакка,
Ә көзне куып җибәрде
Бик-бик еракка.

Ландыш ГАЙНЕТДИНОВА.
Өгерҗе, Кырынды.

Ә СИН «САБАНТУЙ»ГА ЯЗЫЛДЫҢМЫ?

ХӨРМӘТЛЕ «САБАНТУЙ» ГАЗЕТАСЫ РЕДАКЦИЯСЕ! Без сиңа беренче тапкыр язабыз. Без матур итеп язарга һәм укырга өйрәндек. Син безнең иң якын дустыбыз. Синең һәр саныңны көтеп алабыз. Быел да классыбыз белән «Сабантуй»га язылдык.

Кошлар да очып китте,
Менә алтын көз килде.
Шундый моңсу, ямансу...
Миңа нишләргә инде?

Без язылдык «Сабантуй»га —
Әле генә, күптән түгел.
Иң күңелле бәйрәм итеп
«Сабантуй»ны көтә күңел.

III класс укучылары.
Мөслим, Олы Чакмак.

Иртәгә, дия-дия, «Сабантуй»га язылырга соңга калмадыңмы, дустым?

Ашык, подписканың соңгы көннәре җитте.

ГАЗЕТАГА ЯРТЫ ЕЛГА ЯЗЫЛУ БӘЯСЕ *8820* СУМ.

Индексы — *54124*.

Министерство связи СССР
„Союзпечать"

АБОНЕМЕНТ на газету / журнал **54124** (индекс издания)

«Сабантуй» (наименование издания) — Количество комплектов: 1

на 1996 год по месяцам

1	2	3	4	5	6	7	8	9	10	11	12

Куда ______ (почтовый индекс) ______ (адрес)

Кому ______ (фамилия инициалы)

ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА

ПВ | место | литер — на газету / журнал **54124** (индекс издания)

«Сабантуй» (наименование издания)

Стоимость	подписки	___ руб. ___ коп.	Количество комплектов	1
	переадресовки	___ руб. ___ коп.		

на 1996 год по месяцам:

1	2	3	4	5	6	7	8	9	10	11	12

Куда ______ (почтовый индекс) ______ (адрес)

Кому ______ (фамилия, инициалы)

«Сабантуй» килгәч...



КАЗАННЫҢ «Төньяк бистәсе» дип аталган ерак почмагында урнашкан 105 нче мәктәпкә тиңләшерлек мәктәп тагын бар микән? Татар телен укытырга тегендә кеше җитми, монда кеше кирәк дип яшәгән заманда, унөч (!) укытучы эшли биредә. Рус мәктәбе булса да, малайлар, кызлар бик матур итеп саф татарча сөйли, җырлый, фикер алыша беләләр икән. Тик менә тере язучыларны бер дә күргәннәре булмаган моңа кадәр. Гөлфия апалары Вәлиевага рәхмәт, «Сабантуй» хезмәткәрләре белән очрашуны ул оештырды. Бигрәк тә мәшһүр шагыйребез Илдар ага Юзеевның килүен балалар бәйрәм төсле кабул иттеләр.

Н. СЕДОВ фоторәсемнәре.



МАЛАЙЛАРГА БЕР КИҢӘШ

БҮГЕН акчаң күп булса гына кибеттән әйбер алып була. Әти-әниләргә дә үз вакытында акча бирмиләр. Малайларга уен кирәк-яраклары алу өчен генә күпме акча кирәк. Аларны күргәч, балачагым искә төште. Аның бигрәк тә кыш айлары. Ул вакытта кибеттән алган кәшәкәле малайны күрү — авыл башына төшкән самолетны күрү белән бер иде. Бөтенебездә дә үзебез ясаган таяклар. Аны эшләве бик җиңел. Сәрби куагының (акация) юанырагын кисеп аласың да өйгә алып кайтасың һәм, берәр җиргә кыстырып, кәшәкә рәвешенә китереп, бөгеп куясың. Бу эшне кичтән башкарсаң, икенче көнне син мәктәптән кайтышка таяк өзер дигән сүз. Кулга балта алып, бөгелгән өлешенең янягын юнасы гына кала. Сынмый да, ярылмый да. Сынса да, куркасы юк, беткәнмени тагын куаклар. Без шайбаларны да кибеттән алмый идек. Өянке кәүсәсендә үскән гөмбәне сугып төшерәсең, менә сиңа шайба. Ә берәрсе сугып җибәргәч, тезгә килеп эләксә, авыртуы кибетнекеннән бер дә ким түгел. Шулай итеп безгә әти-әнигә ялынырга да, аларның кесәләрен такырайтырга да туры килми иде. Малайлар, сезгә дә шулай эшләргә киңәш итәм.

Радик МӨХӘММӘТҖАНОВ.
Арча.

ПРОВЕРЬТЕ ПРАВИЛЬНОСТЬ ОФОРМЛЕНИЯ АБОНЕМЕНТА!

На абонементе должен быть проставлен оттиск кассовой машины.

При оформлении подписки (переадресовки) без кассовой машины на абонементе проставляется оттиск календарного штемпеля отделения связи. В этом случае абонемент выдается подписчику с квитанцией об оплате стоимости подписки (переадресовки).

Для оформления подписки на газету или журнал, а также для переадресования издания бланк абонемента с доставочной карточкой заполняется подписчиком чернилами, разборчиво, без сокращений, в соответствии с условиями, изложенными в каталогах Союзпечати.

Заполнение месячных клеток при переадресовании издания, а также клетки «ПВ—МЕСТО» производится работниками предприятий связи и Союзпечати.

Күзләремне ачтыгыз



«ӘДӘБИЯТ» әдәп сүзеннән алынган. Димәк, аның рухы кешене әдәпле итеп тәрбияләү, әхлакны төзәтү»,— диеп башлап җибәрде Мәдинә апа безнең сыйныфтагы беренче дәресен. Шул беренче сүзләреннән үк укытучы апам минем күңелемне яулап алды.

Мин Октябрь районының Түбән Норлат мәктәбендә 9 ел укып, 10 нчыга Казандагы Ш. Мәрҗани исемендәге 2 нче татар гимназиясенә килдем. Теләгем — тулырак белем туплап, югары уку йортына керү. Мине бигрәк тә татар әдәбияты дәресләре җәлеп итте. Авыл мәктәбендәге һәм мондагы дәресләр арасындагы аерма җир белән күк кебек иде. Беренчедән, ул кабинет җиһазларыннан ук күзгә ташлана. Бирегә чит кеше килеп кергәч, аны «менә бу рус теле кабинеты» дип таныштырсаң, ул сиңа: «Җүләр микән әллә бу?» диеп карап куяр иде. Чөнки стеналарда татар әдәбияты классикларының портретлары, әдипләребезнең канатлы сүзләре, китап киштәләрендә — китаплары тезелеп киткән.

Мәдинә апа Гарифуллина үткәргән әдәбият дәресләрендә мин чын мәгънәсендә татар әдәбиятының асылын аңладым. Ул дәресләрдә мин Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Дәрдмәнд, С. Рәмиев кебек олы шәхесләр, күбесенең моңарчы сөйләнгән коры биографияләре белән генә түгел, элек телгә дә алынмаган тормышлары, иҗатлары, әсәрләре белән дә таныштым. Мәдинә апа ул яңалыкларны төрле чыганаклардан эзләп табып безгә сөйли, бу әдипләр яшәгән йортларга — музейларга алып бара, аларның спектакльләренә йөртә иде.

Ә инде 11 нче сыйныфта безне Өлфәт абый Закирҗанов үзенең сөйләме, әдәбият өлкәсендәге яңалыклары, фикерләре белән таң калдырды. Күптән укылган әсәрләрне яңа күзлектән укырга, яңача карарга өйрәтте. Хәзерге заман татар әдәбияты, аны әйдәп баручы шәхесләр белән ныклап таныштырды.

Мин Мәдинә апага, Өлфәт абыйга чиксез рәхмәт-ихтирамымны белдерәсем килә. Сез минем күземне ачкан, олы тормышка аяк басканда ярдәм кулын сузган, киңәшләрегез белән булышкан олы йөрәкле кешеләр. Рәхмәт сезгә, рәхмәт чын күңелдән.

Люция СӘЙФЕТДИНОВА,
КДУ студенты.



ТУҢДЫРМАНЫ КЕМ УЙЛАП ТАПКАН?

Кытайлардыр дигән фараз бар. Алар бит бик борынгыдан җимеш суларын туңдыра белгәннәр.

Тарихчылар сөйлиләр: борынгы Рим императоры Нерон тәмле ашарга бик яраткан, туңдырылган тәм-том турында ишеткәч, үзенең хезмәтчеләрен чәчәк сулары, бал һәм җимешләр кушып ясалган ширбәтне туңдыру өчен кар җыярга җибәргән. Рим дәүләте җиңелгәч, ширбәт рецептын гарәпләр дә белгәннәр дип уйланыла. XVI гасырның икенче яртысында атаклы Екатерина Медичи туенда туңдырма бирелгәнлеге билгеле. Шуннан соң Франциядә бер генә мәҗлес тә бу нигъмәттән башка узмаган.

Ә Англиягә ул 100 ел үткәч кенә килгән. Америкада нибары XVIII гасырда гына туңдырманың ни икәнлеген белгәннәр.

Вафлядан ясалган стаканга туңдырма 1914 елда гына салына һәм бик күпләргә ошый. Ә «саплы» эскимо 1919 елда барлыкка килә. Ә хәзер туңдырманың нинди генә төрләре юк!



КОФЕЛЫ ТУҢДЫРМА

Кофега кайнап чыккан су салыгыз. Йомыркаларны шикәр комы белән болгатып туглагыз. Аннары шуңа кайнар кофены өстәгез. Әйбәтләп болгатып, суыткычка куегыз. Каймакны туглап күпертегез, шуңа кофелы, йомыркалы әзер катнашманы салып болгатыгыз. Матур савытларга — өлешләргә бүлеп салып чыгыгыз һәм суыткычның иң суык урынына урнаштырыгыз. Табынга биргәндә өстенә уылган шоколад валчыгы сибәргә дә онытмагыз.

4 йомырка, 100 г шикәр, 50 г кофе (тиз эри торган), 1/2 су, 200 г каймак, шоколад кирәк булыр.

ҖИЛӘК СУЫННАН ТУҢДЫРМА


Теләсә кайсы җиләк суын формаларга салып, суыткычның иң суык урынына куегыз. Катып киткәнче болгатып торыгыз. Бик тәмле туңдырма — җиләк туңдырмасы килеп чыгар.

ШОКОЛАДЛЫ ТУҢДЫРМА

Җылымса сөткә шикәр комы, уылган шоколад валчыгы өстәгез. Шоколадны су «мунча»сы ясап эретегез, аннан суытыгыз. Аннары бу массага күпертелгән каймак салып болгатыгыз һәм суыткычка куеп катырыгыз.

100 г шоколад, 3 аш кашыгы шикәр комы, ярты стакан сөт, 1 стакан каймак кирәк булыр.

60. ТАТАРСТАН — КАРА АЛТЫН ИЛЕ





Искәндәр ИСМАИЛИ

БЕЗНЕҢ РЕСПУБЛИКАБЫЗДА бик күп табигый байлыклар тупланган. Алар арасында иң кыйммәтлесе — нефть. «Кара алтын» дип йөртәләр аны. Нефть турында кайбер нәрсәләрне безнең болгар бабаларыбыз да белгән. Җир астыннан саркып чыгучы куе кара сыеклыкны сугыш вакытында кулланганнар (яндыргыч снарядлар ясаганнар), ягулык итеп файдаланганнар. 19 гасыр урталарында хәзерге Кама Тамагы районының Сөкәй авылы янында табылган нефть ятмаларын эшкәртү буенча заводлар да төзелә. Тик алар бөтен көченә эшләп китә алмыйлар, чөнки куәтле нефть ятмаларын эзләү бик акрын бара.

Совет власте елларында Татарстан җирендә нефть промышленностен булдыру өчен күп эшләр эшләнә. Академик И. М. Губкин җитәкчелегендәге геологлар, махсус тикшеренүләр үткәргәннән соң, Идел белән Урал арасында бик зур нефть ятмалары булырга тиеш, дигән нәтиҗәгә киләләр. Казан университеты профессоры Е. И. Тихвинская 1934 елда ук инде шушындый нефть ятмаларының иң куәтлесе Ромашкино авылы янында тупланган булуын исбатлый.

Ләкин боларның барысы да бит әле кәгазьдә генә. Хәзер инде галимнәрнең күрсәтмәләре буенча скважиналар белән җирне бораулап, тирән катламнарга үтеп кереп, нефтьне чынбарлыкта табарга кирәк.

Сугыш алды еллары. Илебезнең төрле почмакларында яңадан-яңа промышленность предприятиеләре калкып чыга. Бөтен җиргә ягулык кирәк. Көтмәгәндә Бөек Ватан сугышы башланып китә. Немец фашистлары Бакуны басып алсалар, нефтьсез калачакбыз. Идел белән Урал арасында «икенче Баку»ны булдырырга кирәк! Алдыбызда шундый максат тора иде.

Киеренке көннәр башлана. Бервакыт бораулаучылар бригадасы тирән катламнан чыккан ниндидер ят токымга тап булалар. Җентекләбрәк карыйлар: кара май тамчылары сеңгән кебек. Нефть түгелме соң бу? Суга салып тикшерәләр — су өсте зәңгәр-яшел шәмәхә төсендәге юка гына элпә белән каплана. Арадан берәү шатланып кычкырып җибәрә:

— Керосин исе килә бит! Нефть!

Иртәрәк шатланганнар икән: Татарстанда бораулаган беренче тирән скважина буш булып чыга. Әмма ләкин каядыр шушы тирәдә генә, һичшиксез, нефть ятмасы табылачагына беркем дә шикләнми иде инде.

Ниһаять, күптән көтелгән вакыйга: 1934 елның 2 августында Шөгер авылы янында Гариф Хәмидуллин җитәкчелегендәге бригада бораулаган скважинадан нефть фонтаны күтәрелә! Шул ук елны бу скважина тәүлегенә 40 тонналап нефть бирә!

Бораулау эшләре республикабызның башка районнарында да нык җәелеп китә. 1946 елда Баулы нефте ачыла. 1948 елда атаклы Ромашкино нефте ташкын булып ургылып ага башлый, Татарстанның чыннан да тиз арада «икенче Баку»га әвереләчәгенә ышаныч арта.

Республикабыз икътисадында өр-яңа тармак — нефть промышленносте барлыкка килә. 1950 елда «Татнефть» берләшмәсе төзелә. Әлмәт, Бөгелмә, Лениногорск, Баулы районнары нефть вышкалары белән тула. 1956 елда Татарстан нефть чыгару буенча (18 миллион тонна!) Советлар Союзында беренче урынга чыга. 1960 елда нефть чыгаруның күләме 46 миллион тоннага, 1970 елда исә 100 миллион тоннага җитә.

Республикабызның нефть районнары берничә дистә ел эчендә бөтенләй үзгәрде, яңа шәһәрләр, эшчеләр поселоклары барлыкка килде. Миңнебай газ эшкәртү заводы, Казан органик синтез заводы, Түбән Кама химкомбинаты, Зәй һәм Урыссу ГРЭСлары да үзләренең барлыкка килүләре белән Татарстан нефтенә бурычлы.

Әйтәсе дә юк, республикабызның данын еракларга таратты безнең нефть. Әмма соңгы елларда шунысы да ачыкланды: үзебезнең Татарстаныбыз өчен артык файдасы булмаган икән аның. Чыннан да, нигә инде шулкадәр күләмдә суыртырга иде ул нефтьне? Үзебездән артканын барыбер бит юк кына бәягә Польша, Германия Демократик Республикасы, Чехословакия, Венгрия кебек «тугандаш» илләргә сатып җибәрдек. Ул вакытларда без, Европадагы яшь социалистик илләргә ярдәм итәбез, дип, чын күңелдән шатлана идек. Чималны, ягъни эшкәртелмәгән нефтьне сату икътисади яктан карaганда бер дә файдалы түгел иде, югыйсә. Үзебездә нефть эшкәртү заводлары төзеп, чит илләргә әзер продукция чыгарсак, никадәр отышлы булыр иде! Шушы көнгә кадәр туган җиребез куеныннан барлыгы 2 миллиардтан артык «кара алтын» суыртып алынган. Хәзер нефть чыгару 1970 нче еллар белән чагыштырганда күпкә кимеде. 1990 елда, мәсәлән, ул 40 миллион тонна чамасы гына, 1992 елда 30 миллионнан да кимрәк булды. Безгә артыгы кирәк тә түгел! Булганын саклап тотарга, акыл белән файдаланырга кирәк.

Тагын бер нәрсәне әйтеп үтми ярамас: соңгы елларга кадәр Татарстан халкы үз байлыгына үзе хуҗа булмады. Нефть белән дә шулай иде. Миллионлаган тонна нефтьнең бер килограммын да үзебез сата алмадык. СССРның Мәскәүдә урнашкан үзәге аны бездән тартып алып, үзе теләгәнчә файдаланды. Хәтта авылларыбызга газ кертү дә чын проблемага әйләнде бит! Аның каравы, миллиардларча кубометр газны чит илләргә озата тордылар. Ә табигатебезгә, җир-суларыбызга килгән зыянзәхмәтләрне исәпли башласаң? Нефть чыга торган якларда күпме чәчү җирләре юкка чыкты, күпме сулыклар пычранды? Чын-чынлап экологик катастрофа булды бу республикабыз өчен.

Татарстан суверен, бәйсез республика дип игълан ителгәч кенә (1990 ел) хөкүмәтебез, үзебездә табылган нефтьнең барысы да халкыбызга хезмәт итәргә тиеш, дигән белдерү белән чыкты. Хәзер шушы бурычны гамәлгә ашыру буенча актив эш алып барыла.

Әнием, әгәр кайтсаң...



Парча

ТАТАРСТАН авылларында йөргәндә, игътибарымны матур хәрефләр белән язылган көндәлек җәлеп итте. Кыз бала көндәлеге иде бу. Еллар узды. Ул кыз хәзер үзе әни булгандыр. Аның исемен үзгәртеп, көндәлектән бераз өзекләр китерәм, вакыйганың асылын язып үтәм. Аның кичерешләренең һәр җөмләсе: *«Әнием, әгәр кайтсаң» — дип башлана.*

Роза әнисен хәтерләми. Аңа 4 айлык вакытта әнисе аны әбисенә биреп җибәргән. Кыз хәзер дәү әнисе тәрбиясендә яши.

— Әнием, әгәр кайтсаң, мин сиңа бер нәрсә дә эшләтмәс идем. Мин хәзер авылда яшим. Саф һава, ипи, бәрәңге, сөт, катык — һәммәсе дә үзебезнеке.

— Әнием, әгәр кайтсаң, шикәр алып кайт, яме. Сездә талонга диләр, ә талоннарны чүплектән дә табарга була икән дип сөйлиләр. Дөресме шул? Азат исемле бергә укучы малай ит талонын безнең авыл урамыннан тапкан да, әнисе белән әтисе Чаллыга барып, ит алып кайтканнар.

— Әнием, әгәр кайтсаң, сине җиләккә алып барыр идем. Мин урманда һәр урынны, яшерен аланнарны беләм. Бервакыт җиләк җыеп йөргәндә, Рево исемле малай 35 градус эсседә туның әйләндереп кигән дә мине куркытырга урманга килгән. Башта бик курыктым, мин аны чын аю дип белдем. Аюга бик охшаган иде шул. Урман булып урманда ничек мине эзләп тапкан диген, ә? Усал малай түгел ул, шаяртып кына шулай киенгән. Әлегә кадәр бу серне беркем дә белми. Рево үзе дә оныткандыр. Мин курыкканга гына шулай истә калгандыр ул.

— Әнием, әгәр кайтсаң, кайтырга акчаң булмаса, үзем салырмын. Мин аена 5 сумга бала карыйм. Барлык җыйган акчаларымны сиңа бирермен. Кайвакытларда синең кайтуыңны төшемдә күрәм дә сөенеп уянам. Син бит дәү әнинең бик тырыш, зиһенле баласы булгансың. Зиһенле кеше адашмый диләр бит. Нишләп адаштың икән син? Кайт инде, кайт, мин сине сагынып көтәм. Бәлкем, син минем бу фани дөньяда яшәвемне дә оныткансыңдыр. Дәү әнинең кочагына кереп сыенам да ул синең турыда сөйли. Ара-тирә мөнәҗәтләрен дә җырлап җибәрә. Дәү әни миччкә якканда, мин иртук торып, аның күргәннәре турында хикәяләрен тыңларга яратам. Кайт инде, әнием, сине дәү әни дә бик сагына. Чишмә сулары эчертер идем үзеңә. Дару үләннәреннән чәйләр дә ясап сыйлар идем. Ә син минем сепараторда сөт өсте чыгаруымны карап торырсың.

— Әнием, әгәр кайтсаң, кадер хөрмәттә кунак булырсың. Мин ерак чишмәдән су ташып мунча ягармын. Аһ, әнием, син белмисең шул авыл мунчасының ләззәтен! Бик рәхәт авылда. Без монда ишекләргә таяк кына кыстырып йөрибез. Ә Казанда 2—3 йозакны 5 минутта ачалар икән, диләр. Җиңел тормыш эзләп, күпме яшь кешеләр харап була.

— Әнием, әгәр кайтсаң, тынычланып, кунак булып, яңадан китәр идең, әгәр дә авыл тормышы иллә дә мәгәр ошамаса. Син минем идәннәрне юмлап юуымны карап торырсың. Кайт инде, кайт, әнием!..»

Розаның йокысы качкан. Төннәрен әнә шулай дәфтәр битләренә матур итеп язарга, әнисе белән сөйләшергә көндәлек булдырган. Үзенең уйларын шул истәлекле дәфтәргә яза торган булган.

Бер Роза гына мыни әниләре кайтуын авылларда, шәһәрләрдә көтүчеләр! Балалар йортларында тилмереп боеккан нәниләр... Үсмәсен иде этиәниләре исән килеш ятим булып, күзгә карап инанучы сабыйлар...

Мәгъфия БОРҺАН.
Казан.

КУТУЙЛАРДАН КҮЧКӘН ЗЫЯЛЫК



БУ ФОТОСУРӘТТӘГЕ кыз балага күз салыгыз әле. Татар халкының яраткан шагыйре Гадел Кутуйның сеңелесе Һава ул.

1926 нчы елда Самара шәһәрендә әлеге фоторәсемгә төшкәндә Һава Кутуевага нибарысы 14 яшь була. Кыз баланың күңел бөреләре уянгаң самими, садә чагы.

Мәгърифәт нуры чәчүче Кутуевлар гаиләсе мәдәниятне, әдәбиятсәнгатебезне, әхлакыбызны баетучы тирән белемле, киң карашлы зыялылар, милли горурлыгыбызны саклап тотучы чын иҗади көчләр була. Әниләре Динә апа һәм әтиләре Нурмөхәммәт абый балаларына төпле белем, матур тәрбия бирергә, әдәбият-сәнгать белән кызыксындырып үстерергә тырышалар. Зәйнәп, Гадел, Һава (Шәмсия исемле кызлары үлә) мәктәптә бик әйбәт укыйлар, укуларын югары билгегә тәмамлыйлар. Гадел, Зәйнәп әдәби түгәрәккә, Һава бию түгәрәгенә йөри. Балалар бер-берсенә булышып, күңел биреп укыйлар.

«Һава аеруча йомшак күңелле, ягымлы, игътибарлы кыз иде,— дип искә ала туганнары.— Гомере буе шундый булып калды: ярдәмчел, кешелекле».

Фарыз гамәлне үтәп, хәрам эштән, намус кушмаган эштән тыелып калу — Кутуевлар нәселенең яшәү кагыйдәсе. Ходай Һава Кутуевага озын гомер бүләк иткән: ул бүген сау-сәламәт килеш Казахстан республикасында, Актүбә шәһәрендә яши. Гомере буе теш врачы булып эшләгән.

Олы апалары Зәйнәп Кутуева да йөз яшенә якынлаша, ул Казанда яши. Аның улы Диас Вәлиев — хәзерге көндә күренекле язучы, оныгы Майя да берничә китап авторы.

Патриот шагыйрь, кесәсендә бронь кәгазе була торып, Бөек Ватан сугышына китә. Польшаның Згеш шәһәрендә ятып калган язучы Гадел Кутуйның яраткан сеңлесе Һава аның шигырьләренең беренче тәнкыйтьчесе дә, тыңлаучысы да була. Ничә еллар сакланып та фотодан иман нуры сирпи, яшүсмер Һава Кутуева йөзендә Кутуйлар нәселенә хас зыялык сизелә.

Равилә МӨБАРӘКШИНА,
Татарстан Дәүләт музее хезмәткәре.

Рәсемдә: Һава Кутуева, Самара, 1926 ел.

Салих Сәйдәшев

АНЫҢ ТУРЫНДА

Салихны көйләр чишмәсе дип атыйсы килә. Ул көйләрне ничек иҗат итим дип газапланмый, ә күңелендәгесен тизрәк ноталарга салу, язып өлгерү мәсьәләсе аны борчый төсле тоела иде.

Мансур Мозаффаров,
композитор, Татарстанның халык артисты.

Татар совет музыка культурасы тарихында композиторлык профессиясе Салих Сәйдәшев исеме белән башлана. Шуңа күрә дә без аны беренче татар профессиональ музыкасын башлап җибәрүче дибез.

Нәҗип Җиһанов,
композитор, СССРның халык артисты.

Мәшһүр композиторыбызның «Галиябану» һәм «Сүнгән йолдызлар» спектакльләренә язган увертюралары татар музыка сәнгатендәге беренче симфоник әсәрләр булып исәпләнә. «Зәңгәр шәл» һәм «Наемщик» татар совет театр сәнгатендәге яңа жанрның — музыкаль драмалар жанрының юлбашы булып санала. Әлеге әсәрләр һәм данлы «Совет Армиясе маршы» белән Салих Сәйдәшев үз иҗат эшчәнлегенең иң югары баскычына күтәрелә.

Җәүдәт Фәйзи,
композитор, Татарстанның халык артисты.

Татар совет музыкасына нигез салучы, беренче татар операларына этәргеч булып торырлык бик күп музыкаль драмалар иҗат иткән Сәйдәшев таланты алдында безнең музыкаль сәнгатебез зур бурычлы.

Гадел Кутуй,
күренекле язучы.

Салих балаларның да якын дусты иде. Мин үз гомеремдә балаларга «сез» дип эндәшкән ике кешене беләм. Берсе — шагыйрь Дәрдмәнд, икенчесе — Салих Сәйдәшев. Безнең ишек алдында һәрчак бала-чага тулып ята иде. Салих шуларның барсы белән дә исәнләшә иде.

Хәким Сәлимҗанов,
Татарстанның халык артисты.

«Ил» спектаклендә Зифабану ролен миңа тапшырдылар. Җырлы роль бу. Мин моны үз тавышыма җайлап җырларга булдым. Салих абый, спектакльнең музыкаль җитәкчесе буларак, «Сандугач»ны минем шулай үземчә эшкәртеп җырлавымны бик хуплады. Ул, гомумән, һәр кешенең — спектакльдәме ул, концерттамы — үз чыгышына иҗади каравын ярата иде. Аның шул сыйфаты миңа яшьтән үк композиторлык оеткысы салды.

Сара Садыйкова,
композитор. Татарстанның халык артисткасы.

Салих Сәйдәшев дирижер гына түгел, ә сәләтле пианист та. Аның матур, йомшак аһәңнәрдән торган төрле нәфис нюансларга бай уены аерылып тора иде. Сәйдәшев бармаклары астында фортепиано җырлый иде.

Ильяс Әүхәдиев,
дирижер, Татарстанның халык артисты.

Сәйдәшев музыкасы үзенең эчкерсезлеге, кешелеклелеге һәм дөреслеге белән дулкынландыра. Композитор татар музыка яңгырашының закончалыгын аерым бер сиземләү белән сизә, аңлый, тоя, үзенең профессионаллар өчен дә, халык өчен дә бер үк дәрәҗәдә кадерле булган гаҗәеп фикерләрен гади генә итеп, халыкчан телдә сөйләп бирә.

Натан Рахлин,
дирижер, СССРның халык артисты.

Читкә барып чыксак, бездән:
— Сез кем?— дип сорадылар.
Без үзебезнең исемнәребезне әйткәнче:
— Без — Тукай,— дидек.— Без — Такташ, без — Җәлил, без — Сәйдәш,— дидек.
Сәнгатьтә кайчак бөеклекне күрсәтү өчен бер әсәр, бер «Шүрәле» җитә. Халкыма мин тора-тора рәхмәт укыйм. Сирәк булса да, ул озын тарихның катлаулы юлында үзенең сүнми торган маякларын тезгән, ул маяклар яналар, берничә гасырга алга чыгып яналар.
Сәйдәш бөек Тукай белән янәшә яна.

Сибгат Хәким,
Татарстанның халык шагыйре.

Без һәммәбез дә, композитор булып шытып чыккан чакта, азмы-күпме Салих Сәйдәшев йогынтысын тоеп бөреләндек.

Рөстәм Яхин,
композитор, Татарстанның халык артисты.

Бүгенге көн иҗатчысы — телиме ул моны, юкмы — үз иҗатында барыбер Сәйдәшкә хас бизәкләр, орнаментлар кулланып эш итә, чөнки чын мәгънәсендә халыкчан композитор булу өчен, халыкның рухи дөньясын белү һәм тою шарт.

Фасил Әхмәтов,
композитор, Татарстанның халык артисты.

(1900—1954)

ТОРМЫШ ҺӘМ ИҖАТ ЮЛЫ

1900 — 3 декабрь — Казанда Салих Җамалетдин улы Сәйдәшев туа.
1913 — мәдрәсәдә укуны тәмамлый. Беренче татар композиторы-пианисты Заһидулла Яруллин белән таныша.
1914 — Казан музыка училищесына укырга керә.
1918—1920 — Кызыл Армия сафында хезмәт итә.
1920 — Оренбургта «Озын сәфәр» исемле беренче җырын иҗат итә.
1922 — Оренбургтан Казанга кайта. Татар дәүләт драма театрында эшли башлый.
1923 — К. Тинчуринның «Казан сөлгесе» комедиясе куела. С. Сәйдәшев музыкаль оформлениесе.
1926 — К. Тинчуринның «Зәңгәр шәл» драмасы С. Сәйдәшев язган музыка белән беренче тапкыр куела.
1928 — Т. Гыйззәтнең «Наемщик» драмасы куела. С. Сәйдәшев музыкасы.
1929 — Казанда «Булат батыр» исемле нәфис фильм күрсәтелә. Ул Сәйдәшев әсәрләреннән өзекләр уйнау белән алып барыла.
1934 — Мәскәү консерваториясе каршындагы Татар опера студиясенә укырга китә.
1937 — Казанга кайта. Яңадан Татар дәүләт драма театрында эшли башлый.
1940 — СССР Композиторлар союзына кабул ителә.
1951 — Татарстанның халык артисты исеме бирелә. Тууына 50 яшь тулуга багышланган тантаналы кичә уздырыла.
1954, 16 декабрь — Мәскәү хирургия институтында каты авырудан соң вафат була.

БАСЫЛЫП ЧЫККАН МУЗЫКАЛЬ ӘСӘРЛӘРЕ

Батырҗан җыры («Наемщик» пьесасыннан). Казан. Таттосиздат... 1945.
ПОХОД маршы. Казан. Таттосиздат. 1945.
Дан сезгә, җиңүчеләр. Казан. Таттосиздат. 1951.
Җырлар һәм арияләр. Казан. Таттосиздат. 1952.
Балалар җырлары. Казан. Таткнигоиздат. 1953.
Марш Советской Армии. Казан, Таткнигоиздат. 1954.
Сайланма әсәрләр. Төзүчесе З. Хәйруллина. Казан. Таткнигоиздат. 1957.
Драма әсәрләреннән увертюралар һәм биюләр. Казан. Татарстан китап нәшрияты. 1970.
Балалар җырлары. Казан. Татарстан китап нәшрияты. 1972.
Без кабызган утлар. Казан. Татарстан китап нәшрияты. 1980.

АНЫҢ ТУРЫНДА ЯЗЫЛГАН ӘДӘБИ ӘСӘРЛӘР

ӘМИРХАН ЕНИКИ. ГӨЛӘНДӘМ ТУТАШ ХАТИРӘСЕ. Кечкенә роман. Казан. Татарстан китап нәшрияты. 1977.
РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН. СӘЙДӘШ. Поэма. Сайланма әсәрләр — 2 нче том. Татарстан китап нәшрияты. 1993.

С. Сәйдәшев белән Т. Гыйззәт «Наемщик» спектакленә репетиция вакытында.

Сулдан уңга: М. Ильдар, Р. Ваһапов, С. Сәйдәшев, А. Шайморатова, Ф. Биккинин.

С. Сәйдәшев белән З. Хәбибуллин.

С. Сәйдәшев укыган мәктәп (хәзерге Тукай урамы, 34 нче йорт).

Сулдан уңга: журналист И. Усманов, С. Сәйдәшев, Г. Кутуй.

С. Сәйдәшев белән К. Тинчурин.

С. Сәйдәшев — почетлы кызылармеец, 1929 ел, март.

Рәсам М. РӘХИМОВ эшләре.

Әкияти Яңа ел

ЯҢА ЕЛ КИЧЕНДӘ ӘДӘБИ-МУЗЫКАЛЬ КОМПОЗИЦИЯ

Залда матур итеп бизәлгән чыршы. Аның тирәсендә әкият геройлары булып киенгән балалар.

АЛЫП БАРУЧЫ.

Каршылыйк, дуслар, бергәләп,
Яңа ел килә безгә.
Әнә күпме кунак килгән
Әйләнә-тирәбезгә.

БЕР БАЛА.

Бүген күңелләр җырга
Һәм биергә җилкенә.
Бүген бездә зур бәйрәм —
Яңа ел килә безгә!

ИКЕНЧЕ БАЛА.

Кыш бабай килгәч, булачак
Котлаулар да, бүләк тә.
Яңа елда чынга ашар
Безнең барлык теләк тә.

3 НЧЕ БАЛА.

Без теләкләр телибез
Бүген бер-беребезгә.
Бәхет елы булып кил
Син туган җиребезгә!

АЛЫП БАРУЧЫ.

Күрегез бу чыршыны!
Чыршының да чып-чынын!
Нинди төз, матур, биек,
Тора түшәмгә тиеп.

(Балалар чыршы тирәли йөриләр).

5 НЧЕ БАЛА.

Ботак саен утлар яна,
Йолдыз балкый иң очында,
Ул бит чыршы,
Горур басып
Тора бүлмә кочагында.

ҖЫР.

(Җырдан соң балалар утырышалар. Чыршы турында шигырьләр сөйлиләр).

АЛЫП БАРУЧЫ. Бәйрәм кичәсен куптән башласак та, нишләптер Кыш бабай белән Кар кызы күренми. Әйдәгез, балалар, чакырыйк әле аларны!

(Кул чабалар, залга Саескан очып керә).

САЕСКАН. А-һа-һай! Ишеттегезме әле?

АЛЫП БАРУЧЫ. Ни булды. Сөйлә инде тизрәк!

САЕСКАН. Кыш бабай белән Кар кызы Яңа ел каршыларга төрле әкиятләрдән дусларын чакырганнар. Сез аларны каршыларга әзер булыгыз.

(Очып китә).

ГӨЛЧӘЧӘК. Урман эче бик якты,
Күктә ай да калыкты.
Көлдән күмәч аламын,
Бәйрәмгә ашыгамын.

(Соры бүре күренә).

БҮРЕ. Көлтә-көлтә койрыгым,
Болгый-болгый улаем.
Күмәчләреңне бирмәсәң,
Калҗа-калҗа тураем.

ГӨЛЧӘЧӘК. Дусларым, яшерегез, мине, соры бүре куып килә!

АЛЫП БАРУЧЫ. Мин сине яшерәм.
Бас минем артыма.

(Бүре килеп җитә).

БАЛАЛАР. Балалар, Гөлчәчәкнең үтеп киткәнен күрмәдегезме?

АЛЫП БАРУЧЫ. Тукта әле, соры бүре. Бүген Яңа ел кичәсе, син Гөлчәчәкне рәнҗетмә. Дуслашыгыз да бәйрәм кичәбезгә рәхим итегез!

АЛЫП БАРУЧЫ. Балалар, бу кунаклар кайсы әкияттән килгәннәр?

БАЛАЛАР. «Гөлчәчәк» әкиятеннән!

(Музыка яңгырый. Камыр батыр керә).

КАМЫР БАТЫР. Ерак юллардан
эһ тә итмичә
Ашыгып килдем, нәни
дусларым.
Егып салырмын
Җилен-яңгырын,
Егып салырмын,
Буранын-карын!

Исәнмесез! Мине таныдыгызмы? Әйе, мин Камыр батыр.

Камыр, камыр диделәр,
Кабарттылар, изделәр.
Көчем барын сизделәр,
Батыр булсын диделәр.
Камырдан пешә икмәк!
Һәркем аннан көч алыр,
Димәк, икмәктә — хикмәт.

«Чабата җыры»

(Кәҗә белән сарыкның җырлап килгәне ишетелә)

КӘҖӘ белән САРЫК. Күп юл уздык, туган илдән ерак киттек,
Алҗып бетте аяклар,
Тузып бетте тояклар.

КӘҖӘ. Нинди куркыныч нәмәрсә бу?

САРЫК. Кәбестәме әллә?

КӘҖӘ. Бу-б-бу...

САРЫК. Бүрекмени?

КӘҖӘ. Бу-бу-бу...

САРЫК. Нәрсә, бүрәнә башы димәкче буласыңмы әллә?

КӘҖӘ. Бу-бу-бу-... ре!

САРЫК. Бүре? Әйдә, качтык!

КӘҖӘ. Тукта, Сарык дус. Бүренең үзе түгел бу, башы гына.

САРЫК. Әйдә, тизрәк сызыйк моннан!

КӘҖӘ. Без бу бүре башын алып капчыкка салыйк. Файдасы тимәсә дә зыяны тимәс, караңгы да төшә башлады. Безгә кунарга урын кирәк бит.

САРЫК. Кара әле, әнә теге урман эчендә нииндидер ут күренә. Караңгы төшкәнче барып җитик.

(Чыршы янында учак. Учак өстендә казан асылган. Дүрт бүре учак тирәли утырганнар. Бүреләр җырлыйлар. Кәҗә белән Сарык килеп керә).

БҮРЕ. Ха! Кайсыгыз әйтте әле ботка белән ашарга ит беткән дип? Сарык белән Кәҗә итеннән кем баш тартыр...

КӘҖӘ. Исәнмесез, бүре дуслар,
Сездә бүген бәйрәм икән.
Бүреләрнең бәйрәмнәре
Бик күңелле, хәйран икән!
Бу бәйрәмгә ямь өстәргә
Килдек без дә Сарык белән.
Ни карыйсың? Тиз бул,
ангыра Сарык,
капчыктагы бүре башын китер,
китер алып!

(Кәҗә бүре башын әйләндереп карый. Сарык кычкыра).

КӘҖӘ. Ми-ки-ки-ки, ми-ки-ки-ки,
капчыктагы бүре башы бит уникe!
Ах, ангыра, җүләр Сарык,
Моннан зуррак бүре башын китер табып!

БҮРЕ. Туктагыз, тиз генә су китерик. Суы бик аз, безнең ботка пешер коры...

(Бүреләр качалар).

КӘҖӘ. Уф, йөрәгем. Куркуымнан менә-менә өзелеп төшә дип торам.

САРЫК. Кызык иттең син бүреләрне, берьюлы качып беттеләр.

Бүреләрне җиңеп булмый кул
көче белән генә.
Бүре бары, бүре башы
Җитте бүре башына.
Безгә калды бүреләрнең
Учагы да, ашы да.
Бә-ә-ә...

АЛЫП БАРУЧЫ. Дуслар,
Яңа ел кичәсенә рәхим итегез!
Яңа ел каршыларга
Җыелдык без бу залга,
Исән-саумы Яңа ел,
Хуш киләсең, уз алга!

Балалар, нишләптер Кыш бабай белән Кар кызы күренми.

БЕРГӘЛӘП. Әйдәгез, Кыш бабайны бергәләп чакырыйк!

Кыш бабай! Кыш бабай!

КЫШ БАБАЙ. Ә-ү-ү! *(Килеп керәләр).*

Менә без дә килеп җиттек. Исәнмесез, Яңа ел котлы булсын!

Дусларым, бәйрәм итик,
Уйныйк, җырлыйк та көлик.
Күтәренке күңел белән
Өр-яңа елга керик!

КАР КЫЗЫ. Кем биергә остарак,
Чыгып бассын уртага!
Музыкантлар уйнасын
Җитезрәк көйләрне.
Әйдә, биик бергәләп,
Тыпырдатып идәнне!

(Чыршы тирәли бергәләшеп бииләр).

1 НЧЕ БАЛА. Әй, Кыш бабай,
Кыш бабай,
Бәйрәмебез Сез килгәч
Матурланды тагын да.
Бик күңелле уйнавы
Яшел чыршы янында.

2 НЧЕ БАЛА. Әй, Кыш бабай,
Кыш бабай,
Безнең сөйгән кунак син.
Ямьле үтсен кичәбез,
Безне көлдер, уйнат син.

(Әйлән-бәйлән уйныйлар).

(Кыш бабай һәм балалар уены. Кыш бабай, Кар кызы, балалар белән чыршы янына утыралар, балалар шигырь сөйлиләр).

КУЯН. Әй, Кыш бабай, Кыш
бабай,
Кыш бабай, юеш бабай.
Без сине яратабыз.
Син бит безгә ел саен
Бүләкләр таратасың.
Бүләкләрең бик тәмле,
Безнең бәйрәм бик ямьле.

КЫШ БАБАЙ. Бу капчыкта сезгә дигән күчтәнәчләр. Әмма капчык гади түгел, серле. Ул табышмак чишә белгәннәргә генә ачыла. Менә сезгә беренче табышмак:

Алгы тәпие кыска,
Чабарга ул бик оста.
Соры тунын сала да,
Ак тунын кия кышка.

Я, бу нәрсә?

БАЛАЛАР. КУЯН!

КЫШ БАБАЙ. Әйе, куян. Куяннарга кишер бүләк итәбез.

(Куяннар биюе. Бию уен белән тәмамлана).

КЫШ БАБАЙ. Менә сезгә икенче табышмак. Ак ашъяулык таптык, җир өстенә яптык. Я бу нәрсә?

БАЛАЛАР. Кар!

КЫШ БАБАЙ. Кар бөртекләренә алтын яңгыр җепләрен бүләк итәбез.

КАР КЫЗЫ. Ай-һай, кар
бөртекләре күп!
Сезгә ак яктылык
Айдан күчкән микәнни?
Айдан матур ак карлар
Айдан төшкән микәнни?

(Кар кызының кар бөртекләре белән биюе. Биюле уен белән тәмамлана).

КЫШ БАБАЙ. Бусы минем көрәк.
Кар көрәргә кирәк
Һәркөн иртүк торып
Йөрим сукмак ерып.

(Кар бөртекләрен бер урынга җыя. Музыка. Кар бөртекләре төрле якка очып китәләр).

АЛЫП БАРУЧЫ. Шаярасың да
уйныйсың
Әйтерсең бу син түгел.
Йөгерә-йөгерә карлар җыйган
Малай кебек син бүген.

КАР КЫЗЫ. Бабакай, әйдә биеп
Чыршыны әйләнәбез,
Тагын да күңеллерәк
Булыр бу бәйрәмебез.

КЫШ БАБАЙ. Юк, миннән
булмый.
Картаеп беттем инде.

(Бию көе яңгырый. Кар кызы кул чаба).

Бие әле, бие әле,
Биеми торма әле.
Яңа ел бәйрәмендә
Сөендер килгәннәрне.

(Кыш бабай, Кар кызы бергәләп бииләр).

КЫШ БАБАЙ. Без бүген җырладык, биедек, уйнадык, күңелле итеп Яңа ел кичәсен үткәрдек. Ябыйк инде, балакайларым, бу Яңа ел бәйрәмен.

АЛЫП БАРУЧЫ. Балаларга алып килгән күчтәнәчләреңне таратырга онытты бит.

КЫШ БАБАЙ. Әй, карт хәтер,
Бар сезгә күчтәнәчләрем, бар!
Кәҗә, Сарык алып керегез әле
теге капчыкларны!

(Ике капчык алып керәләр).

КЫШ БАБАЙ. Җаныма шатлык
тулсын,
Капчык чишелеп торсын!
Нинди әйбер капчыкта,
Кала күрмик хурлыкка!

(Төрле әйберләр чыгара, икенче капчыкны ачып карый).

КЫШ БАБАЙ. Менә бу капчыкта
Яңа ел бүләкләре.

(Бүләк тарата).

1 НЧЕ БАЛА. Рәхмәт, рәхмәт,
күп бүләк
Китергәнсең безгә син.
Без нәни дусларыңны
Сөендерим дигәнсең.

КЫШ БАБАЙ. Сау булыгыз,
балалар,
Сау булыгыз, кунаклар,
Киләсе елга кадәр!

С. БАЯЗИТОВА.
197 нче балалар бакчасы, Казан.

Бәхет китер, Яңа ел!

ИНСЦЕНИРОВКА

Катнашалар:	Назлыгөл
Әтәч	Биюче кыз
Эт	Яңа ел киемендәге малай
Куян	Солдат киемендәге ике малай
Бүре	1 нче солдат
Аю	2 нче солдат
Кыш бабай	
Гармунчы малай	
Гөлчәчәк	

ЯҢА ЕЛНЫ каршы алыр өчен бизәлгән зал. Бик матур уенчыклар тагылган чыршы куелган. Стена буйларында — эскәмияләр. Хайваннар булып катнашкан балалар битлек *(маска)* кигәннәр, койрык такканнар. Әтәч белән эт сәхнәнең икесе ике ягыннан чыгалар. Сәхнә уртасында очрашалар.

ЭТ. Ау-ау! Кая барасың, сырлы кикрик!

ӘТӘЧ. Кик-ри-күк! Яңа елны каршыларга барам, Алабай.

ЭТ. Ау-ау! Яңа ел белән тизрәк очрашасың килсә, ул якка барма.

ӘТӘЧ. Ку-ку-ку! Кая таба барырга?

ЭТ *(көнчыгыш якка күрсәтә).* Бу якка бар. Әй, онытып торам икән, сезнең халык кичкә таба күрми башлый бит әле.

ӘТӘЧ. Ә син нишләп йөрисең, Алабай?

ЭТ. Мин дә Яңа елны каршыларга чыктым.

ӘТӘЧ. Алай булса, бергә барыйк?

ЭТ. Мин кешеләрне көтәм әле.

(Эскәмиягә барып утыра).

ӘТӘЧ. Мин дә кешеләрне көтим.

(Эскәмиянең икенче башына утыра. Сөйләнә-сөйләнә куян керә).

КУЯН. Их! Киче лә, киче! Тып-тын гына, җилсез генә... Их! *(Җырлый)*

Әнә килә автомобиль
Төягәннәр куяннар.
Куяннарга ашар өчен
«Сникерс» куйганнар. Их!

ЭТ. Без кешеләрне көтәбез. Син дә тын гына утырып көт әйдә, кыска койрык!

КУЯН. Утырам. Нигә утырмаска... *(Эскәмиягә утыра).*

(Гармун тоткан малай белән Кыш бабай керә).

КЫШ БАБАЙ. Шушы чыршы янында көтик әле Яңа елны.

МАЛАЙ. Әйе, шушында көтик шул. Бездән дә алданрак килүчеләр дә бар икән. Саумысыз, чибәркәйләр!

(Этнең башыннан сыйпап куя).

ЭТ. Ау-ау!

ӘТӘЧ. Ки-ки-ри-күк!

КУЯН. *(Бик нечкә тавыш белән).*

Саумысез, Кыш бабай!

КЫШ БАБАЙ. Саумысыз барыгыз да!
Я әле, улым, уйнап җибәр гармуныңны.
Бәйрәм ямьле булсын.

МАЛАЙ. Була ул, Кыш бабай. *(Үзе уйнап, үзе җырлый).*

Гармун телләре сайрыйдыр
Бәйрәм ямьле үтәр дип.
Иске елны озатабыз,
Ул кайтмаска китә бит.

КЫШ БАБАЙ. Шулай. Кайтмаска китә шул.

(Гөлчәчәк белән Назлыгөл керәләр. Алар артык кыска итәк кигәннәр).

ГӨЛЧӘЧӘК *(тыйнак кына).* Саумысез, Кыш бабай.

НАЗЛЫГӨЛ. / КЫШ БАБАЙ. } Саумысыз, балалар! Сез кая юл тоттыгыз?

ГӨЛЧӘЧӘК. Без Яңа елны каршыларга чыктык.

КЫШ БАБАЙ. *(Итәкләренә ишарәләп)* Шушылаймы? Ярамый, балакайлар. Кызларга мондый кыска киемне кояшта кызынганда гына киярге ярыйдыр, кеше күрмәгән урында гына. Яңа ел сезгә карарга оялыр бит.

НАЗЛЫГӨЛ. Алай булса, без хәзер...

(Күтәрелгән итәкләрен төшерәләр, озын итәкләр килешеп тора).

КЫШ БАБАЙ. Менә бит, нинди матур булдыгыз. Инде Яңа елны каршылау кичәсендә нинди һөнәрегезне күрсәтергә телисез?

ГӨЛЧӘЧӘК. Без җырлый беләбез.

КЫШ БАБАЙ. Бик әйбәт. Җырыгызны тыңлап карыйк.

ГӨЛЧӘЧӘК *(җырлый).*

Толпар килә атлап-атлап,
Энҗе карларны таптап.
Карлар булып явар идем,
Булса дөньяны пакълап.

КЫШ БАБАЙ. Рәхмәт, кызым. Булыр дөньяны пакълап. Булырга тиеш... *(Назлыгөлгә).* Инде син җырла, матуркай.

НАЗЛЫГӨЛ *(җырлый).*

Күңел көлә челтәр карлар
Керфекләремә кунса;
Бөртек кардай эрер идем,
Җирдә тынычлык булса.

КЫШ БАБАЙ. Матур җырлыйсыз, кызлар. Рәхмәт сезгә. Гел шатлыклы җырлар җырлап үтсен гомерегез Яңа елда.

(Аю керә).

АЮ. У-у-у-у! Хәерле кич!

КЫШ БАБАЙ. Хәерле булсын берүк. Әйдә, ялкау, ишек төбендә торма. Түргә уз. Йокыңнан айнып килүеңә рәхмәт.

АЮ. У-у-у-у! Бәйрәм бит.

КЫШ БАБАЙ. Бәйрәм шатлыгыннан бер биеп ал әле, ялкау. Сезнең нәселне биергә оста диләр бит.

АЮ. Анысы булыр. *(Аю бик тә әкрен биеп китә. Сәхнәдәгеләр кул чабалар. Бераз биегәч, аю биегән көйгә бию хәрәкәтләре ясап, милли кием кигән биюче бер кыз чыга. Аны күргәч, аю туктап карап тора да, эскәмиягә барып утыра. Гармун җиңел бию көе уйный. Кыз милли бию башкара.*

КЫШ БАБАЙ. Рәхмәт, балакай. Яңа елда да, шатланып биеп үтсен гомерең.

(Бүре керә. Куян куркып сикереп тора да, эт артына барып посып утыра).

~~КЫШ БАБАЙ. Рәхим ит, бүре дус!~~

БҮРЕ. У-у-у-у! Яңа ел барыбызга да дуслык китерсен!

КЫШ БАБАЙ. Изге теләгең өчен рәхмәт. Барыбыз да бер кояш астында яшибез. Дуслык булса гына яшәү ямьле була. Дуслык бик кирәк, бүре дус. Без Яңа елны каршыларга җыелдык. Кем нинди һөнәр күрсәтә ала, шуны да карыйбыз. ~~Бүре дә үз~~ һөнәрен күрсәтер дип уйлыйбыз.

~~БҮРЕ *(аптырап).* Мин ни...~~ ни... *(Башын ике бот ~~арасына куеп, сырты белән~~ тәгәрәп китә. Һәммәсе дә*

Дәвамы җиденче биттә.

Архив









БЕЛӘСЕЗМЕ, китаплар да авырый икән бит. Озак еллар яшәгән китапларга төрле микроблар иярәшә, имеш. Ул китапларны махсус чистарту камераларында шул микроблардан арындыралар ди.

Туктагыз, гел киресеннән башладым бугай, аңлатыбрак сөйлим әле. Татарстан Фәннәр академиясенең кульъязма һәм архив бүлегендә кунакта булдык без. Мөхтәрәм язучыларыбыз белән бергәләп татар архивы белән танышттык. Әлеге бүлекнең мөдире Нил Юзиев һәм өлкән фәнни хезмәткәр Марсель Әхмәтҗанов мондагы яңалыклар турында гаять кызыклы итеп сөйләде.

Танышу әлеге дә баягы «дезинфикацион камера»дан башланды. Экспедициядән эзләп табып кайткан китап-кульъязмаларны иң әүвәл биредә «мунча кертәләр» икән. Аннан соң «чистартылган кунак», махсус папкаларга теркәлеп, фондка китә.

Фонд нәрсә соң ул, дип сорыйсызмы? Һәр язучыга аерым бер фонд бирелә. Ягъни анда язучының бөтен әйберләре — әсәрләре, кульъязмалары, хатлары, документ, фотолары саклана. Бүген биредә 160 лап фонд исәпләнә. Мәсәлән, 9 номерлы фонд — Тукайныкы, 10 — Җәлилнеке һ. б. Халкыбызның мәдәни культурасын күрсәтә торган бик зур хәзинәбез бар безнең. Күз алдыгызга китерегез: 50 меңнән артык кульъязма бар биредә. Әле тасвирланмаганнарын да исәпләсәң, 100 меңнән арта. Ел саен меңгә якын укучы-аспирант, архив материалларын өйрәнеп, фәнгә яңалык кертә икән.

Мирасханәнең төп сакчысы Марсель Әхмәтҗанов фидакарьләрчә эшләп, берүзе генә дә 2 меңләп кульъязма юллап кайткан.

Бер кызыклы вакыйга. Әле күптән түгел генә Ленин урамындагы бер йорттан Фәтхи Бурнашның архивын тапканнар. Төрле-төрле хатлар, фотолар, документлардан торган җиде арыш капчыгын көч-хәл белән күтәреп кергәннәр монда.

Күптәнге язучы-шагыйрьләребезнең архивы әйбәт саклана, әлбәттә. Ә бүген иҗат итүче әдипләребезнең хәзинәсе бармы соң биредә?

— Исәннәрдән Риза ага Ишморат, Туфан Миңнуллин, Нурихан Фәттах, Илдар Юзеев һ. б. күп кенә язучы-шагыйрьләребез кульъязмаларын китерде,— диде Марсель абый.

— Кульъязма, хатлардан тыш, тагын нәрсәләр кирәк?— дип кызыксынды Гариф ага Ахунов.

— Шәҗәрәләр бик кирәк. Документ, фото, укучы хатлары, хәтта командировка кәгазьләре дә ярый. Әле күптән түгел генә Ибраһим Сәләховның үзе язган һәм аңа язган 4000 ләп хатын таптык...

Архивта хәзинә чиксез. Әмма дөньяга чыкмаган кульъязмалар да бихисап әле. Боларны эшләүче энтузиастлар, фанатлар җитешми. Сөйләшүдән соң архив киштәләре арасына кердек. Тарих исе аңкып торган калын-калын китаплар. Казанның революциягә кадәрге зур картасы, Муса Җәлилнең обой кәгазенә үз кулы белән язган сугышка кадәрге кульъязмалары, идәннән түшәмгә кадәр җиткән шәҗәрәләр...

Халкыбызның бай мирасын чагылдыручы хәзинәләр тын гына киштәләрдә ята.

А. ГЫЙМАДИЕВ.

Рәсемдә: архивта кунакта.
Н. СЕДОВ фоторәсеме.

Башы алтынчы биттә.

көләләр. Кул чабалар).

КЫШ БАБАЙ. Рәхмәт. Белгән белгәнен эшли, белмәгән — беләгеен тешли, диләр бит.

(Хәрби киемдә ике солдат малай керә. Алар коралсызлар).

СОЛДАТЛАР. Честь бирәбез, Кыш бабай!

КЫШ БАБАЙ. Сәламәтлек телим. Менә солдатлар да килеп җиттеләр. Коралларыгызны күрмим, солдатлар.

БЕРЕНЧЕ СОЛДАТ. Без коралларны ташладык, Кыш бабай!

ИКЕНЧЕ СОЛДАТ. Хәзер тынычлыкны корал белән саклап булмый, хөрмәтлебез.

КЫШ БАБАЙ. Алай икән... Ә ничек сакларга уйлыйсыз тынычлыкны?

БЕРЕНЧЕ СОЛДАТ. Тынычлыкны саклар өчен акыл кирәк.

ИКЕНЧЕ СОЛДАТ. Без Яңа елдан акыл сорарга килдек.

БЕРЕНЧЕ СОЛДАТ. Әйе, акыл сорарга килдек, Кыш бабай!

КЫШ БАБАЙ. Сугыш коралын ташларга акылыгыз җиткән. Рәхмәт, солдатлар. Тынычлыкны акыл белән ничек сакларга кирәген дә табарсыз кебек күренәсез. Әйе, Яңа ел ярдәм итәр, Ходай кушса.

СОЛДАТЛАР. Амин! Ярдәм итә күрсен иде инде, Кыш бабай.

КЫШ БАБАЙ. Теләгебезне Аллаһы Тәгалә ишетер. Өметебезне сүндермик. Без монда Яңа ел килеп җиткәнче һөнәрләребезне барлыйбыз. Солдатлар да буш кул белән килмәгәннәрдер.

БЕРЕНЧЕ СОЛДАТ. Мин шигырь сөйли беләм.

ИКЕНЧЕ СОЛДАТ. Мин дә.

(Сәхнә артыннан кыңгырау чыңы, ат тояклары тавышы ишетелә).

КЫШ БАБАЙ. Ишетәсезме?! Бу — ул. Яңа ел килә. Мин каршы алырга чыгыйм. Ә сез, кадерле солдатлар, шигырь сөйли торыгыз. (Кыш бабай чыгып китә).

БЕРЕНЧЕ СОЛДАТ. И Яңа ел!

Шундый сафлык китер,
Яңа ел таңына тиң булсын.
Ак бәхетләр булып яусын карлар,
Явызлыклар калсын, күмелсен.

ИКЕНЧЕ СОЛДАТ. Яңа елым!

Безгә акыл китер?
Һәммәбезгә булсын җитәрлек.
Акылсызлар явын юл яздырып,
Яшәү йөген төяп үтәрлек.

(Кул чабалар. Пауза. Һәммәсенең күзләре ишектә).

БАРЫСЫ БЕРГӘ. Яңа ел килә!

СОЛДАТЛАР. Рәхим ит, 1996 нчы ел!

(Иңбашына 5—6 яшьлек малай — Яңа елны утыртып Кыш бабай керә. Сәхнәдәгеләр алкышлыйлар).

ЯҢА ЕЛ. Мин сезгә бүләккә һәммәгезгә җитәрлек олы бәхет алып килдем.

БАЛАЛАР. Рәхмәт, Яңа ел!

(Алкышлыйлар).

Әкълимә САЯПОВА.
Башкортстан, Яңавыл.

КЕЧКЕНӘ СОЛТАН ЯЗДЫРГАН ШИГЫРЬЛӘР

Сез инде «Сабантуй» газетасын алдыргач, мөгаен, шигырь-хикәяләр дә яратасыздыр. Күп итеп китаплар да укыйсыз булыр. Ә менә китапларыгыз арасында Нурия Измайлова-Мирзаянованың җыентыклары бар идеме? Исегезгә төшерим әле, бәлки, китап исемнәре буенча хәтерләрсез: «Яратам», «Алтын тарак», «Минем җәй», «Иң серле әкиятем», «Мин зур үскәч», «Җирдә» һ. б.

Моңа кадәр укырга өлгермәгән булсагыз, бүген үк китапханәгә барып, эзләп карагыз. Эзләгән — тапмый калмас. Балалар өчен язылган «Мин зур үскәч» дип исемләнгән шигырьләр җыентыгын очратсагыз — бигрәк тә шәп. Сер итеп кенә әйтим, андагы шигырьләрнең бик күбесе олы улы Искәндәр белән кечесе Солтанга багышланган.

— Улларына ничә яшь?— дип сорыйсызмы?

Олы улы XI класста, Америкада укый. Әмма соңгы елы түгел. Чөнки Америкада бездәге урта мәктәп кебек уку йорты унике еллык бит. Ә кечкенәсе Мәскәүдәге балалар бакчасына йөри. Әнисенә шигырь, сюжетлар бүләк итә, сабыйлыгы белән сабырсызландыра. Телевизордагы мультфильмнар карамагында, әнисенең аяк арасында «чуалып» йөрмәгәндә, рәсемнәр ясый. Рәсемнәрендә машиналар да машиналар. «КамАЗ», «Волга», «Тайото», «Мерседес», «Джип», «Вольво», «Форд»...

Самолет, вертолет, поездлар да ясый икән әле Солтан. Кайберләренә үзе утырып та йөргәч, якыннан таныш булгач, бигрәк матур килеп чыга. Әнисенең җырлап торган шигырьләре кебек.

Солтанның тагы бер сере бар бит әле. Аның исеме Нурия апагызның кайнатасы хөрмәтенә куелган. «Искиткеч әйбәт кеше иде»,— дип сөйли Солтан бабайның килене. Димәк, нәни Солтан алар нәселендәге кемнең исемен йөртә инде? Шагыйрә апагызның менә шул улына багышлап язган шигырьләрен укып карагыз әле. Аларның моңлы яңгырашына, спайлыгына, җай белән генә сезне тәрбия итүенә үзегез дә ышанырсыз. Киләчәктә йөгерек телле, җор сүзле, акыллы кеше булып үсәсегез килсә, НУРИЯ ИЗМАЙЛОВА-МИРЗАЯНОВАНЫҢ шигырьләрен уку бик кирәк сезгә!

Эльмира апагыз
ШӘРИФУЛЛИНА,
Казан-Мәскәү-Казан.

Нурия Измайлова-Мирзаянованың шигырьләрен сигезенче биттән укый аласыз.

Монда кызык, чөнки...

Казансу ярындагы кызыл төстәге мәһабәт бинага күз салганыгыз бармы сезнең? Милли мәдәни үзәк бу.Ниләр бар соң монда?

Балалар өчен һәрдаим эшләп килгән «Колобок» мультфильмнар салоны яшь тамашачыны күптәннән үзенә тартты. Мультфильм геройларры күбесе диярлек татар телендә сөйләшә.

Өлкән класслар өчен махсус лекторийлар ачылды: кызыксындырган сорауларның күбесенә җавап алырга була монда.

Милли мәдәни үзәктә күргәзмәләрнең дә әһәмияте зур. «Шәҗәрә» күргәзмәсе бик күп укучыларны җәлеп итте. Егерме ике нәсел шәҗәрәсе белән танышу эзсез үтми — алар үзләре дә шәҗәрә төзеп башта мәктәп-гимназияләрдә, аннан соң милли-мәдәни үзәктә узган конкурсларда катнашалар.

«Милли сәнгать энҗеләре» күргәзмә залында сынлы сәнгатьнең иң гүзәл үрнәкләре: төрле шамаилләр, борынгы болгар сәнгать әсәрләре урнашкан. Балачактан таныш «Саксок», халкыбызның горур, гүзәл хатын-кызы «Сөембикә» скульптура әсәрләре балаларны бигрәк тә җәлеп итә, алар үз фикерләрен белдерәләр.

Күргәзмәләр белән таныштыру татар һәм рус телләрендә алып барыла, ә керү — бушлай.

Яңадан-яңа кызыклы, мавыктыргыч ял итү чаралары, уен, конкурслар әзерли милли мәдәни үзәк. Мәсәлән, 27 декабрьдән 9 гыйнварга чаклы узачак чыршы бәйрәме күңелле ял вәгъдә итә. Милли мәдәни үзәкнең директор урынбасары Халисә Исмәгыйлева сүзләренә караганда, балалар белән иҗади эшчәнлек алып барып, аларда милли рух тәрбияләү бу үзәкнең максаты булып тора.

Гөлүсә ЗАКИРОВА,
КДПУ студенты.

Нурия Измайлова-Мирзаянова шигырьләре

МАЙМЫЛ

Маймыл, маймыл, шимпанзе!
Башларыңда ни кайгы?
Ямьсезмен дисеңмени?
Ятиммен дисеңмени?

Моңаеп утыргач гел,
Шул да булдымы маймыл!

Маймыл бит ул шук була,
Сикерә дә сикерә,
Ыргыта да очыра,
Ирәя дә очына
Һәм тынламый берсен дә!

Безгә син шундый кирәк,
Авызыңны ер тизрәк!

Ямьсез булу кая соң!
Шундый матур шаян син!
Шаяннар ямьсез булмый,
Шаяннар ялгыз булмый.
Ятиммен дип уйлама,
Безнең белән булганда.
Без дә нәкъ синең кебек —
Әйдә, уйныйк сикереп!

ЯҢГЫР КОЯ

Әй, тышта яңгыр коя!
Урамнар елап тора:
Елый яфрак, үләннәр,
Стеналар, түбәләр,
Елый кояш һәм болыт,
Яшьләр тама: тып-тып-тып.

Тышта яңгыр булганга
Чыгалмыйбыз урамга.
Безне сагынып урамнар
Шулай елап торалар.

ӘНЕМ БЕЛӘН БЕЗ

Без энеле-агалы,
Без аклы да каралы.
Ак малай — минем энем,
Сокланып туялмыймын!
Битенә битне куям —
Ах, нинди йомшак куян!

Кара малай — мин булам.
Ә карага ни булган!
Мин бит «абый» атлымын,
Карамын һәм катымын!
Ул нинди абый кеше,
Булса ак куян ише!

ТӨЗӘТӘМ

Төзәтергә яратам мин,
Төзәтәм дә төзәтәм.
Яңартам уенчыкларны,
Үзгәртәм дә үзгәртәм.
Тәгәрмәчләр алыштырам,
Алыштырам кузовлар.
Уенчыкны төзәтмәсәң,
Уйнап нинди кызык бар!
Борып куям, кагып куям,
Белем бөтен җирләрен.
Үзем хуҗа, белем ничек
Төзәтергә кирәген.
«Ватасың гына бит!»— диләр,
Ватмагачтын бернине,
Ничек итеп төзәтәсең
Ватылмаган әйберне?

МАШИНА АЛА БЕЛМИСЕЗ

Ватык минем машиналар,
Нигә миңа андыйлар!
«Барыбер ватасың!» диеп,
Яңаларын алмыйлар!
Йөрми минем машиналар,
Барсы да тәгәрмәчсез,
Шоферсыз кабиналары,
Рульсез дә тәрәзәсез...
Мин аларны ватканмындыр
Бәләкәй булган чакта,
Әле миңа бер генә яшь
Я ике тулган чакта.
Хәзер үзегез дә мине
«Өч яшьлек егет!»— дисез,
Егетләргә машинаны
Ала гына белмисез:
Үземнән дә зур булсын ул,
Мин ваталмаслык булсын!
Нихәтле такси урамда!
Алыгыз шуның берсен!



САМОЛЕТ, ВЕРТОЛЕТ!

Самолет, вертолет!
Бир канат, бир канат!
Аяк талды күп йөреп,
Ял итим күккә менеп.
Болытларга утырып,
Йолдызларга тотынып,
Җилләр белән кушылып,
Кошлар белән дус булып!

Ял итәсем бик килә,
Ял итәлмим тик кенә.
Ятып кояш өстенә,
Очып йөрисем килә.

Самолет, вертолет!
Бир канат, бир канат!
Телем талды кычкырып,
Төшче монда, күк болыт!
Өйрәт мине очарга,
Бер канатсыз булсаң да!

КОЯШ ТӨШӘ

Тау артыннан чыга да,
Озын нурлар суза да,
Кояш төшә урамга,
Кояш төшә елгага,
Кояш төшә сиңа да,
Кояш төшә миңа да.

Юкка артык батыр ул —
Җиргә төшәр — батылыр!
Суга төшәр — сүнәр ул,
Күккә ничек менәр ул?!

Егылып китә инде!
Коелып бетә инде!

Яратсам да төшкәнен,
Баеганын көтәмен.
Төн кояшны кочаклый,
Егылып төшүдән саклый.
Кояш чыгар иртәгә!
Исән торыр иртәнгә!
Шуннан мин дә тынычлыйм,
Тынычлап ятып йоклыйм.

АВЫЛГА

Поезд, поезд, автобус!
Без авылга кайтабыз!
Нәнәй торган авылга,
Бабай торган авылга,
Бәч-бәч булган авылга,
Кәҗ-кәҗ булган авылга,
Әтәч булган авылга!
Атлар булган авылга,
Матай булган авылга!—
Атларга атланырга,
Матайга атланырга —
Без кайтабыз авылга,
Без кайтабыз авылга!
Бакча булган авылга,
Мунча булган авылга,
Мунча булган авылга,—
Башта бакча утарга,
Аннан чәт-чәт итәргә.
Күп иттереп эшләргә,
Нык иттереп үсәргә!

АҠ БУЯУ

Кыш килде, кыш килде
Ак буяулары белән,
Ак юрганнары белән,
Ак бураннары белән,
Ак урамнары белән,
Ак урманнары белән,
Ак куяннары белән.

Кар яуды, кар яуды,
Бөтен нәрсә агарды!

Яз җитәр, кар китәр,
Ак буяу агып бетәр.
Ак бураннар да булмас,
Ак урамнар да булмас,
Ак урманнар да булмас,
Ак куяннар да булмас.

Ул кадәре ак буяу
Кайда җыелыр икән?
Бөтен диңгез-океан
Ап-актан булыр микән?

БЕЗ ЧӘБӘКӘЙ ИТӘБЕЗ

Чәп-чәп чәбәкәй,
Минем энем бәләкәй.
Ул — акыллы, ул — тәтәй,
Килмә монда, кәҗәкәй!

Кәҗәкәй, кәҗәләтә,
Үпкәләтә, җылата,
Җүнсезлеккә өйрәтә,
Кәйсезлеккә өйрәтә.
«Юк!» диергә өйрәтә,
«Кит!» диергә өйрәтә,
«Тфу!» диергә өйрәтә,
Очындыра, ирәйтә,
Тәтиләрне кыйната,
«Ыргыт!» диеп өйрәтә...
Әни әйтә: «Йокла, йокла!»,
Кәҗә: «Ела!» дип әйтә!
Башта үзе котырта,
Башта үзе дус итә,
Әни почмакка бастыргач,
Ярдәм итми бөртек тә...

Уйныйбыз да көлебез
Уенчыклар белән без.
Чәп-чәп чәбәкәй
Итеп уйный белебез!
Чәп-чәп чәбәкәй,
Килмә монда, кәҗәкәй!

Баш мөхәррир
Ләлә ГЫЙМАДИЕВА
Шеф-мөхәррир
Роберт МИҢНУЛЛИН
Редколлегия: Марат БАРИЕВ, Шәукәт ГАЛИЕВ, Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ, Ләбибә ИСХАНОВА, Равил РАХМАНИ, Илдар ЮЗЕЕВ.



«Сабантуй»ның оештыручылар — Татарстанның Мәгариф министрлыгы, Яшьләр оешмалары советы, Балалар фонды һәм редакциянең хезмәт коллективы. 1924—90 елларда «Яшь ленинчы» исеме белән чыкты.

Индекс — 54124. Тираж 10000.



Адрес: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.

Телефоннар:
49-36-86, 49-36-90,
49-36-77, 49-36-88,
49-36-94, 53-57-37.

Ярдәм итәргә теләсәгез:
р/счет 700161998/2345716
в Волжско-Камском акционерном банке РКЦ ГЦБ г. Казани МФО 265005 «Для фонда редакции».



Татарстан газета-журналлар нәшрияты типографиясендә басылды.
Газета ТР Матбугат һәм информация министрлыгында теркәлгән. Теркәү таныклыгының номеры 458.

Заказ 1883

Басарга кул куелды: 1995 ел, 9 декабрь 15 сәгать.